КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 декабрь г.Казань № 1701

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына:

ел саен, 5 декабрьгә кадәр, Татарстан Республикасының экспорт потенциалын үстерү һәм Татарстан компанияләренең киләсе елга тышкы базарга чыгуына ярдәм итү планын Татарстан Республикасы Экспорт советына раслауга билгеләнгән тәртиптә кертергә;

90 көн эчендә «2024 – 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы проектын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен (2025 елга кадәр Татарстан Республикасында экспортны үстерү стратегиясен) раслау турында» 2018 ел, 18 июнь, 492 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 декабрь, 1701 нче
карары белән расланды

# 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясе

## I. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә «Уңайлы, нәтиҗәле хезмәт һәм уңышлы эшкуарлык» илкүләм максаты кысаларында чимал булмаган энергетикага карамаган товарларны экспортлауның реаль үсеше 2020 ел күрсәткече белән чагыштырганда кимендә 70 процент тәшкил итәргә тиеш.

Куелган максатка ирешү өчен экспортны алга таба үстерү һәм илебез җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтү системасын алга таба үстерү белән беррәттән Россия конкурентлыкка сәләтле продукциясенең яңа экспортерлары санын арттыру буенча эзлекле эш алып бару зарур. Россия Федерациясе субъектларының экспорт потенциалын нәтиҗәлерәк файдалануга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларын экспорт эшчәнлегенә актив җәлеп итүгә аерым басым ясарга кирәк, чөнки икътисадның нәкъ менә әлеге секторы чимал булмаган энергетикага карамаган экспортын, шулай ук хезмәтләр экспортын үстерүнең иң зур потенциалына ия.

«Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыяте, иң яхшы практикалардан файдаланып, Россия Федерациясе субъектларында институциональ экспорт мохитен камилләштерүгә юнәлдерелгән төбәк экспорты стандартын эшләде.

Әлеге документ экспорт эшчәнлеген активлаштыруга ярдәм итә торган чаралар комплексын тасвирлый, аларны уңышлы гамәлгә ашыру экспортны яклауның нәтиҗәле инфраструктурасын формалаштырырга һәм экспорт эшчәнлеген яклау һәм үстерү өлкәсендә төбәк сәясәтен гамәлгә ашыру процессына Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнарын һәм бизнес-бергәлек вәкилләрен җәлеп итүне тәэмин итәргә һәм, нәтиҗә буларак, экспортерлар санын һәм экспорт продукциясе күләмен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

«Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проекты буенча проект комитетының читтән торып үткәрелгән утырышы беркетмәсе белән Россия Федерациясе субъектларында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңай шартлар тудыру стандартының яңа редакциясе расланды (алга таба – 2.0 версиядәге Төбәк экспорт стандарты).

2.0 версиядәге Төбәк экспорт стандартының максаты – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары компанияләрнең экспорт эшчәнлеген стимуллаштырырга, шулай ук экспортны ярдәм күрсәтә торган нәтиҗәле инфраструктура булдырырга мөмкинлек бирә торган чаралар комплексын ныгыту.

2.0 версиядәге Төбәк экспорт стандарты «Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проекты составына керүче «Халыкара кооперация һәм экспортны үстерү системалы чаралары» федераль проектының паспорты нигезендә эшләнгән.

Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә тышкы икътисадый эшчәнлекне планлаштыру өлкәсендә норматив хокукый база булдыру зарурлыгы яңа икътисадый һәм геосәяси каршылыклар, дөньякүләм финанс һәм товар базарларының тотрыксызлыгы, шулай ук икътисадның реаль секторына тискәре йогынты ясый торган һәм тышкы сәүдә операцияләрен гамәлгә ашыра торган эпидемиологик вәзгыять барлыкка килү белән аңлатыла. Финанс үстерү инструментларын да кертеп, экспортка ярдәм итүнең комплекслы инфраструктурасын булдыру төбәк икътисадының тотрыклылыгын күтәрү һәм төбәк бюджетының керемлелеген арттыру өчен кирәкле шарт булып тора.

Шулай итеп, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясе (алга таба – Стратегия) Татарстан Республикасында чимал булмаган энергетика карамаган экспорт һәм оешмалар хезмәтләре экспорты күләмен 2020 елга карата 70 процентка кадәр арттыру өчен шартлар тудыру.

Стратегияне эшләүнең хокукый нигезен һәм төбәк сәнәгать сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләүче төп документлар:

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 316 номерлы карары белән расланган «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасы;

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе;

«Халыкара кооперация һәм экспорт», «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасын үстерү» милли проектлары;

«Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проектының проект комитеты утырышының 2022 елның 2 сентябрендәге 5 номерлы беркетмәсе белән расланган 2.0 версиядәге Төбәк экспорт стандартында тәкъдим ителгән стратегик ориентирлар.

Стратегия Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый элемтәләрен үстерү һәм ныгыту, Татарстан Республикасы продукциясен сату базарларын һәм аның экспорт потенциалын киңәйтү;

экспортка ярдәм итү инфраструктурасының нәтиҗәлелеген арттыру, административ каршылыкларны ачыклау, киметү һәм экспортны үстерү мәсьәләләре буенча федераль һәм республика башкарма хакимият органнары һәм эшкуарлык

субъектлары арасындагы хезмәттәшлек механизмнарын камилләштерү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларын экспорт эшчәнлегенә актив җәлеп итү;

экспортның географик диверсификациясе өчен уңайлы шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән продукцияне халыкара базарларга чыгаруга юнәлдерелгән чараларны чит илләрдә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә үткәрү;

Татарстан Республикасы экспортерларына халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларына чыгуда ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасында оешмалар өчен ел саен экспорт эшчәнлеге нигезләрен өйрәтү, шул исәптән аларны акселерация программаларында катнашуга җәлеп итү;

Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын булдыру.

## II. Татарстан Республикасы тышкы икътисадый эшчәнлегенең төп юнәлешләре торышын анализлау

Татарстан Республикасы тышкы икътисадый әйләнешенең төп күрсәткечләре.

Идел буе таможня идарәсе мәгълүматлары буенча 2020 елга Татарстан Республикасының тышкы сәүдә әйләнеше 12,4 млрд. АКШ доллары тәшкил итте һәм 2019 ел белән чагыштырганда гомуми күләмнән (3 676 106,4 мең АКШ доллары) 22,9 процентка кимеде. Шул ук вакытта экспорт аның гомуми күләменнән 31,4 процентка кимеде һәм 8,8 млрд. АКШ доллары тәшкил итте, импорт аның гомуми күләменнән 14,9 процентка артты һәм 3,6 млрд. АКШ долларына тигез булды.

Идел буе федераль округының тышкы сәүдәсендә Татарстан Республикасының тышкы сәүдә әйләнеше өлеше гомуми күләмнән 27,53 процент тәшкил итте.

Татарстан Республикасының сәүдә балансы сальдосы уңай булды һәм 5,08 млрд. АКШ доллары тәшкил итте; 2019 ел белән чагыштырганда 4,6 млрд. АКШ долларына (гомуми күләмнән 47,6 процент) кимеде.

2021 елга Татарстан Республикасының тышкы сәүдә әйләнеше 17,5 млрд. АКШ доллары тәшкил итте һәм 2020 ел белән чагыштырганда гомуми күләмнән 40,8 процентка артты, шул исәптән экспорт – 12,07 млрд. АКШ доллары, ул экспортның гомуми күләменнән 36,8 процентка артты, һәм импорт – 5,5 млрд. АКШ доллары, ул импортның гомуми күләменнән 50,4 процентка артты.

Идел буе федераль округының тышкы сәүдәсендә Татарстан Республикасының тышкы сәүдә әйләнеше өлеше гомуми күләмнән 28,52 процент тәшкил итте.

Татарстан Республикасының сәүдә балансы сальдосы уңай булды һәм 6,6 млрд. АКШ доллары тәшкил итте; 2020 ел белән чагыштырганда 1,4 млрд. АКШ долларына (гомуми күләмнән +27,3 процент) артты.

### Экспортның һәм импортның товар структурасы

2020 ел

Экспортның товар структурасы

2020 елга Татарстан Республикасы экспортының товар структурасында минераль продуктлар – экспортның гомуми күләменнән 69,2 процент; химия сәнәгате продукциясе, каучук – экспортның гомуми күләменнән 19,2 процент өстенлек итте.

Импортның товар структурасы

Импортның товар структурасында әйдәп баручы урынны машина төзелеше продукциясе – импортның гомуми күләменнән 66,4 процент; химия сәнәгате продукциясе, каучук – импортның гомуми күләменнән 18,0 процент, металл һәм алардан эшләнмәләр – импортның гомуми күләменнән 7,1 процент алдылар.

1 нче таблица

Экспортның һәм импортның товар структурасы
Татарстан Республикасы,
2020 елның гыйнвары – декабре

(мең АКШ доллары)

| Евразия икътисадый берлегенең тышкы икътисадый эшчәнлегенең товар номенклатурасы кодлары | Товар исеме | Барлыгы | | Ерак чит илләр | | Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | экспорт | импорт | экспорт | импорт | экспорт | импорт |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 01-24 | Азык-төлек товарлары һәм авыл хуҗалыгы чималы (текстильдән башка) | 283 737,7 | 67 373,8 | 181 504,4 | 36 882,4 | 102 233,4 | 30 491,4 |
| 25-27 | Минераль продуктлар | 6 039 023,4 | 31 813,9 | 5 416 460,2 | 19 602,2 | 622 563,2 | 12 211,6 |
| 27 | Ягулык-энергетика товарлары | 6 027 066,3 | 25 420,1 | 5 406 156,5 | 16 847,4 | 620 909,8 | 8 572,7 |
| 28-40 | Химия сәнәгате продукциясе, каучук | 1 676 519,6 | 656 539 | 1 169 831,7 | 617 919,7 | 506 687,9 | 38 619,3 |
| 41-43 | Күн чималы, җәнлек тиреләре һәм алардан эшләнмәләр | 145,2 | 4 433,9 | 102,6 | 4 379,3 | 42,6 | 54,5 |
| 44-49 | Агач һәм целлюлоза-кәгазь эшләнмәләр | 121 073,7 | 31 198,2 | 48 270,7 | 28 587,3 | 72 802,9 | 2 610,9 |
| 50-67 | Текстиль, текстиль эшләнмәләр һәм аяк киемнәре | 14 808,8 | 74 222 | 1 222,4 | 52 153,3 | 13 586,5 | 22 068,7 |
| 72-83 | Металл һәм алардан эшләнмәләр | 109 413,6 | 256 674 | 17 830,9 | 221 199,2 | 91 582,7 | 35 474,7 |
| 84-90 | Машиналар, җиһазлар һәм транспорт чаралары | 440 370,6 | 2 415 760,6 | 111 234,1 | 2 277 049,9 | 329 136,5 | 138 710,7 |
| 68-71, 91-97 | Башка товарлар | 35 786,4 | 102 442,1 | 22 265,2 | 97 332,5 | 135 21,3 | 5 109,6 |

2021 ел

Экспортның товар структурасы

2021 елга Татарстан Республикасы экспортының товар структурасында минераль продуктлар – экспортның гомуми күләменнән 68,8 процент; химия сәнәгате продукциясе, каучук – экспортның гомуми күләменнән 19,2 процент өстенлек итте.

Импортның товар структурасы

Импортның товар структурасында әйдәп баручы урынны машиналар, җиһаз һәм транспорт чаралары – импортның гомуми күләменнән 69,8 процент; химия сәнәгате продукциясе, каучук – импортның гомуми күләменнән 16,5 процент алдылар.

2 нче таблица

Татарстан Республикасы экспортының һәм импортының товар структурасы,

2022 елның гыйнвары – декабре

(мең АКШ доллары)

| Евразия икътисадый берлегенең тышкы икътисадый эшчәнлегенең товар номенклатурасы кодлары | Товар исеме | Барлыгы | | Ерак чит илләр | | Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | экспорт | импорт | экспорт | импорт | экспорт | импорт |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 01-24 | Азык-төлек товарлары һәм авыл хуҗалыгы чималы (текстильдән башка) | 393 015,3 | 80 683,6 | 271 686,7 | 44 770,8 | 121 328,6 | 35 912,8 |
| 25-27 | Минераль продуктлар | 8 300 720,8 | 63 424,7 | 7 967 919,2 | 28 755,6 | 332 801,5 | 34 669 |
| 27 | Ягулык-энергетика товарлары | 8 277 603,3 | 56 364,1 | 7 946 091,2 | 25 081 | 331 512 | 31 283,2 |
| 28-40 | Химия сәнәгате продукциясе, каучук | 2 320 073,8 | 900 997 | 1 673 882 | 856 487,8 | 646 191,8 | 44 509,2 |
| 41-43 | Күн чималы, җәнлек тиреләре һәм алардан эшләнмәләр | 651,8 | 12 831,2 | 419,2 | 12 710,7 | 232,5 | 120,4 |
| 44-49 | Агач һәм целлюлоза-кәгазь эшләнмәләр | 167 459,1 | 37 855,8 | 68 188,1 | 31 016,4 | 99 271 | 6 839,4 |
| 50-67 | Текстиль, текстиль эшләнмәләр һәм аяк киемнәре | 16 032,4 | 66 038,1 | 247,9 | 40 528,4 | 15 784,6 | 25 509,7 |
| 72-83 | Металл һәм алардан эшләнмәләр | 143 024,3 | 341 080,2 | 49 481,5 | 296 853,8 | 93 542,8 | 44 226,4 |
| 84-90 | Машиналар, җиһазлар һәм транспорт чаралары | 651 424,7 | 3 816 734,5 | 209 620,9 | 3 671 159,8 | 441 803,8 | 145 574,7 |
| 68-71, 91-97 | Башка товарлар | 80 117,1 | 152 623,7 | 61 391,8 | 145 746,3 | 18 725,3 | 6 877,4 |

2022 ел

Экспортның товар структурасы

2022 елга Татарстан Республикасы экспортының товар структурасында минераль продуктлар – экспортның гомуми күләменнән 78,3 процент; химия сәнәгате продукциясе, каучук – экспортның гомуми күләменнән 13,4 процент өстенлек итте.

Импортның товар структурасы

Импортның товар структурасында әйдәп баручы урынны машиналар, җайланмалар һәм транспорт чаралар – импортның гомуми күләменнән 51,3 процент; химия сәнәгате продукциясе, каучук – импортның гомуми күләменнән 30,8 процент, металл һәм алардан эшләнмәләр – импортның гомуми күләменнән 7,6 процент алдылар.

Экспортның товар структурасы

2022 ел




Импортның товар структурасы

2022 ел




Графикларда китерелгән мәгълүматлар Татарстан Республикасы Таможня идарәсе хисабыннан алынды.

COVID-19 яңа коронавирус инфекциясе пандемиясе Россия Федерациясе эчендә икътисадка гына түгел, башка илләр белән товар әйләнешенә дә йогынты ясады. Экспорт һәм импортның структурасы, шулай ук товарларның төрле төркемнәренә аларның бүленеше үзгәрде.

2020 елның гыйнварыннан декабренә кадәр Татарстан Республикасы предприятиеләре 2 933,8 мең тонна нефть (2019 ел дәрәҗәсенә карата экспортның гомуми күләменнән 53,4 процент), 3 007,1 мең тонна нефть продуктлары (2019 ел дәрәҗәсенә карата гомуми күләменнән 72,3 проценты) чит илләргә чыгарды.

2020 елда Татарстан Республикасының алдынгы сәүдә партнерлары – 166 ил, экспорт сәүдә операцияләре – 139 илдән, импорт сәүдә операцияләре – 132 илдән гамәлгә ашырылды.

2020 елда товарлар күбесенчә түбәндәге илләргә чыгарылды: Польша (экспортның гомуми күләменнән 17,8 процент), Нидерланды (экспортның гомуми күләменнән 12,7 процент), Беларусь (экспортның гомуми күләменнән 7,8 процент), Казахстан (экспортның гомуми күләменнән 6,9 процент), Германия (экспортның гомуми күләменнән 6,6 процент), Берләшкән Корольлек (экспортның гомуми күләменнән 4,4 процент), Словакия (экспортның гомуми күләменнән 3,2 процент), Венгрия (экспортның гомуми күләменнән  3,0 процент), Бельгия (экспортның гомуми күләменнән 2,5 процент), Финляндия (экспортның гомуми күләменнән 2,3 процент), Болгария (экспортның гомуми күләменнән 2,3 процент), Китай (экспортның гомуми күләменнән 2,2 процент), Франция (экспортның гомуми күләменнән 2,2 процент), Швейцария (экспортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Турция (экспортның гомуми күләменнән 1,6 процент), Үзбәкстан (экспортның гомуми күләменнән 1,5 процент), Һиндистан (экспортның гомуми күләменнән 1,4 процент), Латвия (экспортның гомуми күләменнән 1,2 процент), Эстония (экспортның гомуми күләменнән 1,2 процент), Ирландия (экспортның гомуми күләменнән 1,1 процент), Италия (экспортның гомуми күләменнән 1,1 процент), Кушма Штатлар (экспортның гомуми күләменнән 1,1 процент).

2020 елда товарлар күбесенчә түбәндәге илләрдән кертелде: Германиядән (импортның гомуми күләменнән 24,5 процент), Китайдан (импортның гомуми күләменнән 16,0 процент), Кушма Штатлардан (импортның гомуми күләменнән 7,4 процент), Италиядән (импортның гомуми күләменнән 6,1 процент), Турциядән (импортның гомуми күләменнән 6,0 процент), Беларусьтан (импортның гомуми күләменнән 5,3 процент), Корея Республикасыннан (импортның гомуми күләменнән 3,2 процент), Бельгиядән (импортның гомуми күләменнән 2,1 процент), Һиндистаннан (импортның гомуми күләменнән 1,8 процент), Франциядән (импортның гомуми күләменнән 1,8 процент), Гонконгтан (импортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Польшадан (импортның гомуми күләменнән 1,6 процент), Япониядән (импортның гомуми күләменнән 1,6 процент), Чехиядән (импортның гомуми күләменнән 1,6 процент), Испаниядән (импортның гомуми күләменнән 1,4 процент), Австриядән (импортның гомуми күләменнән 1,4 процент), Берләшкән Корольлектән (импортның гомуми күләменнән 1,3 процент), Нидерландиядән (импортның гомуми күләменнән 1,1 процент).

Тышкы базарда химия производствосы продукциясен куллануга ихтыяҗ зур. Республика химия производствосының чит илләргә чыгарыла торган төп товарлары:

синтетик каучук, автомобиль шиннары, пластмасса һәм алардан ясалган әйберләр, органик химия кушылмалары (шул исәптән циклик углеводородлар), органик булмаган химия продуктлары, өске актив матдәләр, юу һәм чистарту чаралары.

2021 елда республиканың төп сәүдә партнерлары ерак чит илләр булды. Татарстан Республикасының товар әйләнешендә аларның өлеше гомуми күләмнән 87,9 процент, шул исәптән экспортта – экспортның гомуми күләменнән 85,3 процент, импортта – импортның гомуми күләменнән 93,7 процент тәшкил итте.

Иң эре сәүдә партнерлары:

чит илгә чыгарганда: Польша (экспортның гомуми күләменнән 21,6 процент), Нидерландия (экспортның гомуми күләменнән 14,9 процент), Германия (экспортның гомуми күләменнән 5,9 процент), Словакия (экспортның гомуми күләменнән 5,8 процент), Беларусь (экспортның гомуми күләменнән 5,3 процент), Казахстан (экспортның гомуми күләменнән 4,8 процент), Венгрия (экспортның гомуми күләменнән 3,0 процент), Франция (экспортның гомуми күләменнән 2,7 процент), Финляндия (экспортның гомуми күләменнән 2,0 процент), Болгария (экспортның гомуми күләменнән 1,9 процент), Турция (экспортның гомуми күләменнән 1,8 процент), Дания (экспортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Швейцария (экспортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Латвия (экспортның гомуми күләменнән 1,5 процент), Һиндистан (экспортның гомуми күләменнән 1,5 процент), Иран (Ислам Республикасы) (экспортның гомуми күләменнән 1,5 процент), Эстония (экспортның гомуми күләменнән 1,4 процент), Литва (экспортның гомуми күләменнән 1,3 процент), Китай (экспортның гомуми күләменнән 1,3 процент), Үзбәкстан (экспортның гомуми күләменнән 1,3 процент), Бельгия (экспортның гомуми күләменнән 1,2 процент), Италия (экспортның гомуми күләменнән 1,2 процент);

чит илдән керткәндә: Германия (импортның гомуми күләменнән 27,7 процент), Китай (импортның гомуми күләменнән 15,8 процент), Кушма Штатлар (импортның гомуми күләменнән 8,3 процент), Турция (импортның гомуми күләменнән 6,2 процент), Италия (импортның гомуми күләменнән 5,0 процент), Беларусь (импортның гомуми күләменнән 4,0 процент), Польша (импортның гомуми күләменнән 2,1 процент), Корея Республикасы (импортның гомуми күләменнән 2,0 процент), Бельгия (импортның гомуми күләменнән 1,9 процент), Чехия (импортның гомуми күләменнән 1,8 процент), Франция (импортның гомуми күләменнән 1,8 процент), Берләшкән Корольлек (импортның гомуми күләменнән 1,8 процент), Япония (импортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Һиндистан (импортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Мексика (импортның гомуми күләменнән 1,6 процент), Австрия (импортның гомуми күләменнән 1,5 процент), Канада (импортның гомуми күләменнән 1,3 процент).

Татарстан Республикасы тышкы сәүдә әйләнешенең географик структурасында 2022 елның гыйнвары – декабрендә ерак чит илләр өлеше гомуми күләмнән 87,2 процент (2021 елның гыйнвары – декабрендә – гомуми күләмнән 88 процент) тәшкил итте. Шул ук вакытта гыйнвардан алып декабрьгә кадәр аларның экспорт күләмендәге өлеше экспортның гомуми күләменнән 2,6 процентка артты, шулай итеп 87,9 процент тәшкил итте, импорт күләмендә импортның гомуми күләменнән

9,8 процентка кимеде, шулай итеп 83,9 процент тәшкил итте.

2022 елда Татарстан Республикасының ерак чит илләр белән тышкы сәүдә әйләнеше, 2021 ел белән чагыштырганда, гомуми күләмнән 7,1 процентка артты. 2022 елда товарларны чит илгә чыгару, 2021 елга карата, экспортның гомуми күләменнән 33,2 процентка артты, импорт аның гомуми күләменнән 45,3 процентка кимеде.

2022 елда БДБ катнашучы дәүләтләр белән тышкы сәүдә әйләнеше, 2021 ел белән чагыштырганда, гомуми күләмнән 14,7 процентка артты. Экспортның әйләнештәге өлеше экспортның гомуми күләменнән 77,8 процент, импорт – импортның гомуми күләменнән 22,2 процент тәшкил итте. Шул рәвешле, ерак чит илләргә, 2021 ел белән чагыштырганда, товарлар 6,7 процентка күбрәк чыгарылды.

2022 елда Татарстан Республикасының сәүдә партнерлары – 157 ил, экспорт сәүдә операцияләре – 137 ил, импорт сәүдә операцияләре 119 ил белән башкарылды.

2022 елга тышкы икътисадый эшчәнлек нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының төп сәүдә партнерлары ерак чит илләр булды. Республиканың товар әйләнешендә аларның өлеше гомуми күләмнән 87,2 процент, шул исәптән экспортта – экспортның гомуми күләменнән 87,9 процент, импортта – импортның гомуми күләменнән 83,9 процент тәшкил итте.

2022 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының экспорт операцияләре буенча иң зур сәүдә партнерлары: Польша (экспортның гомуми күләменнән 24,4 процент), Нидерланды (экспортның гомуми күләменнән 14,2 процент), Германия (экспортның гомуми күләменнән 7,5 процент), Турция (экспортның гомуми күләменнән 6,2 процент), Венгрия (экспортның гомуми күләменнән 6,1 процент), Словакия (экспортның гомуми күләменнән 4,8 процент), Казахстан (экспортның гомуми күләменнән 4,3 процент), Финляндия (экспортның гомуми күләменнән 4,0 процент), Беларусь (экспортның гомуми күләменнән 3,0 процент), Франция (экспортның гомуми күләменнән 2,8 процент), Латвия (экспортның гомуми күләменнән 2,2 процент), Китай (экспортның гомуми күләменнән 2,1 процент), Бельгия (экспортның гомуми күләменнән 1,7 процент), Үзбәкстан (экспортның гомуми күләменнән 1,4 процент), Һиндистан (экспортның гомуми күләменнән 1,4 процент). Чит илләрдән кайтарту буенча: Китай (импортның гомуми күләменнән 38,5 процент), Беларусь (импортның гомуми күләменнән 10,3 процент), Германия (импортның гомуми күләменнән 9,8 процент), Төркия (импортның гомуми күләменнән 6,9 процент), Корея Республикасы (импортның гомуми күләменнән 3,2 процент), Италия (импортның гомуми күләменнән 2,9 процент), Казахстан (импортның гомуми күләменнән 2,6 процент), Кушма Штатлар (импортның гомуми күләменнән 2,6 процент), Үзбәкстан (импортның гомуми күләменнән 2,2 процент), Һиндистан (импортның гомуми күләменнән 1,9 процент), Индонезия (импортның гомуми күләменнән 1,2 процент), Япония (импортның гомуми күләменнән 1,2 процент), Таиланд (импортның гомуми күләменнән 1,1 процент), Швейцария (импортның гомуми күләменнән 1,1 процент).

2022 елда җитештерүнең чит илләрдән кертелә торган әйберләр логистикасы һәм алар белән тәэмин итүдәге өзеклекләр белән бәйле проблемалар кичерә торган оешмаларга аерым игътибар бирелә башлады.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы вәкиллекләре тарафыннан алар булган илләрдә һәм субъектларында потенциаль партнерларны эзләү эше алып барыла, БДБ, Якын Көнчыгыш һәм Азия илләре аша товарлар кайтарту ихтималы чылбырлары эшләнә, логистика буенча партнерлар эзләү башкарыла.

Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең төп тенденцияләре.

Татарстан Республикасының сәнәгать профиле ягулык һәм нефть химиясе тармаклары белән билгеләнә (нефть чыгару һәм эшкәртү, нефть эшкәртү продуктларының киң спектрын: синтетик каучук, шин, полистирол, полиэтилен һ.б. җитештерү). Шулай ук машина төзелеше дә үсеш алды; авыр йөк машиналары, вертолетлар, самолетлар һәм авиадвигательләр, нефть һәм газ кудыру җайланмалары, елга һәм диңгез суднолары, тракторлар, җиңел автомобильләр җитештерелә.

2022 елның гыйнвары – декабрендә Татарстан Республикасында үзебездә җитештерелгән, төяп җибәрелгән товарлар, башкарылган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләме 4 623,9 млрд.сум, сәнәгать җитештерүе индексы 106,6 процент тәшкил итте.

2022 елның гыйнвары – декабрендә Татарстан Республикасында 35,7 млн.тонна нефть чыгарылды, бу үткән ел белән чагыштырганда 3,5 процентка күбрәк, шул исәптән «Татнефть» ГАҖнең иң зур республика компаниясе тарафыннан 28,6 млн.тонна нефть чыгарылды.

Кече компанияләр тарафыннан 7,1 млн.тонна нефть чыгарылды. 2022 елда кече компанияләр чыгарган нефтьнең чагыштырма күләме Татарстан Республикасы буенча чыгарылган нефтьнең гомуми күләменнән 20 процент тәшкил итте.

Тармак предприятиеләре тарафыннан 1 026,8 млрд.сумга продукция төяп җибәрелде. Сәнәгать җитештерүе индексы 124,8 % тәшкил итте.

52 619 йөк автомобиле һәм 217 җиңел автомобиль, 13,7 млн.шин, покрышкалар, резина камералары, 694,7 мең тонна синтетик каучук, 28 млрд. кВт/сәг электр энергиясе, 54,6 млн.Гкал пар һәм кайнар су җитештерелде.

Татарстан Республикасындагы оешмаларның экспорт продукциясенең перспективалы тармаклары: минераль продуктлар, ягулык, машиналар, җиһазлар, приборлар һәм транспорт чаралары, агач һәм аны эшкәртү продуктлары, агросәнәгать комплексы продукциясе, химия һәм нефть химиясе сәнәгате, резинадан һәм пластиктан эшләнгән әйберләр җитештерү.

## III. Социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру

2022 елда геосәяси факторлар белән бәйле билгесезлек шартлары югары дәрәҗәдә булу ил өчен җитди сынауга әверелде. Моңа кадәр беркайчан да гамәлгә кертелмәгән санкцияләр кертелү Татарстан Республикасы икътисады үсешенә шактый йогынты ясый:

тышкы сәүдә эшчәнлеген чикләү һәм транспорт блокадасы экспорт-импорт операцияләрендә чагыла;

технологик чикләүләр инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга йогынты ясый;

сорау һәм тәкъдимнәр дисбалансы шартларында инфляция басымы, нефтькә

бәяләрнең һәм сум курсының волатильлеге эшлекле активлыкка йогынты ясый;

Россия компанияләре һәм банкларының глобаль финанс системасына керүен чикләү чит ил контрагентлары белән түләүләр уздырганда шактый кыенлыклар һәм чыгымнар тудыра.

Санкция басымы шартларында Татарстан Республикасындагы оешмалар яңа кооперация элемтәләре урнаштыру, логистик чылбырларны яңадан булдыру, яңа сату базарларын эзләү, импортны алыштыру эшләрен оператив рәвештә оештырдылар.

Татарстан Республикасында оешмаларның экспорт потенциалын арттыруда һәм җитештерелә торган продукцияне алга этәрүгә түбәндәге чаралар каралды:

Татарстан Республикасында оешмаларны, шул исәптән кече һәм урта бизнес оешмаларын экспорт эшчәнлегенә җәлеп итү;

«Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыяте белән берлектә гамәлгә ашырыла торган укыту буенча федераль партнерлык программалары кысаларында тренинглар уздыру;

Татарстан Республикасында оешмалар персоналын да, дәүләт хакимияте органнарының тышкы икътисадый эшчәнлектә катнашучы хезмәткәрләрен дә укыту максатында белем бирү курслары һәм семинарлар уздыру;

Татарстан Республикасында «Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проектын гамәлгә ашыру программасын эшләү һәм мониторингы функциясен үтәүче идарәче команда формалаштыру;

экспортка юнәлтелгән предприятиеләргә мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү һәм тышкы икътисадый эшчәнлекне мәгълүмати-аналитик тәэмин итү.

Дөньякүләм нефть базарының уңай булмаган бәя конъюнктурасы шартларында тышкы сәүдә республиканың икътисадый үсешен мөһим чимал ресурсы итеп тәэмин итмәячәк. Димәк, Татарстан Республикасы экспортының нигезе өстәмә кыйммәткә ия товарлар булырга тиеш.

«Үсеш полюсы» төбәкнең потенциалы, югары өстәлгән бәяле продукция җитештерүне арттыру инновацияләрне үстерү һәм җитештерүне концентрацияләү өчен алшартлар тудыра торган сәнәгать кластерлары, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларын кластерлар кысаларында җитештерү кооперациясенә кертү исәбенә.

Әйтик, нефть сәнәгатендә ягулык-энергетика комплексының экспорт потенциалы артуга эре нефть чыгару районнарында гамәлдәге нефть химиясе оешмаларын үстерүгә һәм яңаларын булдыруга, перспективада төбәк нефть химиясе кластерларын оештыруга ярдәм итәчәк.

Татарстан Республикасында оешмаларның конкурентлык сәләтен арттыру буенча эшнең мөһим юнәлешләре түбәндәгеләр:

дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, венчур финанслауны да кертеп, инновация эшчәнлеген интенсификацияләү;

транспорт инфраструктурасын алга таба үстерү һәм модернизацияләү, ул Россиянең Европа өлешендәге мөһим елгалар - Идел һәм Кама буйлап транспорт коммуникацияләре белән «Көнбатыш - Көнчыгыш» һәм «Төньяк - Көньяк» халыкара транспорт коридоры перспективасында проектлана торган Татарстан Республикасының транзит потенциалын тулысынча гамәлгә ашырырга тиеш;

югары технологияле тармакларны да, традицион кулланучылар хезмәтләре секторын да кертеп, хуҗалык эшчәнлегенең төрле өлкәләрен үз эченә алган кече эшкуарлыкны үстерү;

федераль һәм региональ дәрәҗәдәге дәүләт ярдәмен алу, яңа югары технологияле продукция эшләүгә юнәлдерелгән проектларны финанслашу шартлары, мөмкин булган иң яхшы технологияләр базасында техник яктан яңадан җиһазландыру һәм конкуренциягә сәләтле производстволар булдыру мәсьәләләре буенча предприятиеләр белән мәгълүмати-консультация эшен дәвам итү.

«Сәнәгать экспорты» федераль проекты кысаларында конкурентлык сәләтен арттыру буенча корпоратив программаларны гамәлгә ашыру максатларында предприятиеләргә ярдәм күрсәтү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов йөкләмәсе буенча «Made in Tatarstan» проекты (madeintatarstan.com) - Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалы турында «Татарстанда эшләнгән» («Made in Tatarstan»)» мәгълүмат ресурсы (алга таба – Портал) гамәлгә ашырыла. Проект «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә.

Портал Татарстан Республикасындагы оешмаларны эчке һәм тышкы базарларга чыгару максатында Татарстан Республикасы делегацияләренең рәсми визитларын оештыру өчен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының эш коралы буларак актив кулланыла.

Төбәк җитештерүчеләре продукциясен тышкы базарга чыгару өчен төбәк җитештерүчеләре продукциясен конкрет экспорт базарына чыгаруга комачаулый торган сәүдә һәм административ киртәләрне бетерү зарури.

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү экспорт эшчәнлеген дәүләт тарафыннан стимулауның һәм экспортка юнәлтелгән предприятиеләргә ярдәм итүнең комплекслы системасы нәтиҗәлелеген арттыруны һәм үстерүне таләп итә. Мондый система Татарстан Республикасының экспорт эшчәнлеген үстерүнең төп бурычларын хәл итәргә ярдәм итәчәк:

Татарстан Республикасының экспорт активлыгын стимуллаштыру һәм экспорт потенциалын үстерү;

Татарстан Республикасының чимал булмаган энергетика экспортын (шул исәптән хезмәт күрсәтүләр экспортын) үстерү;

югары технологияле экспорт өлешен арттыру.

Төбәктә экспортка юнәлтелгән предприятиеләргә ярдәм, шул исәптән Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген башлап җибәрүгә һәм киңәйтүгә комачаулый торган киртәләрне җиңү максаты белән булышлык күрсәтү Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының ведомство буйсынуындагы «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең (алга таба – ККМК) Экспортка ярдәм үзәге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

«Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыяте – Россия экспортерларына финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларының киң спектрын тәкъдим итә торган чимал булмаган экспортка ярдәм итү дәүләт институты. «Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыятенә мөрәҗәгать итеп, экспортер мәгълүмати, консультация хезмәтләреннән һәм турыдан-туры субсидия ярдәменнән файдаланырга мөмкин.

«Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» ККМКнең Экспортка

ярдәм үзәге экспортка юнәлтелгән предприятиеләргә экспорт циклының теләсә кайсы этабында ярдәм күрсәтә. Экспортка юнәлтелгән эшкуарлыкка ярдәм чараларын гамәлгә ашыру җирле җитештерүчеләрнең яңа базарларга чыгу мөмкинлеген һәм товарларының конкурентлык сәләтен арттыруны тәэмин итә, шулай ук төбәкнең гомуми социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясый.

Моннан тыш, Татарстан Республикасының экспортка юнәлтелгән предприятиеләренә экспорт эшчәнлеген башлап җибәрүгә һәм киңәйтүгә комачаулый торган киртәләрне ерып чыгу максатларында «Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыятенә ярдәм чаралары кулланылачак.

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерүнең төп өстенлекләре түбәндәге юнәлешләр буенча билгеләнде:

сәнәгать тармакларында, авыл хуҗалыгында, глобаль конкурентлыкка сәләтле чимал булмаган секторлар хезмәтләре өлкәсендә формалашу максатларында «Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проектын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруда катнашу;

товарлар, эшләр, хезмәтләр экспортын киңәйтү;

Татарстан товарларының, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең тышкы базарларда булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының экспортка юнәлтелгән предприятиеләренә ярдәм чараларын камилләштерү;

экспортка юнәлтелгән компанияләргә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру максатларында дәүләт хакимиятенең федераль органнары, үсеш институтлары, аерым алганда «Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыяте белән, Россия Федерациясенең чит ил дәүләтләрендәге сәүдә вәкиллекләре һәм башка экспорт үстерү институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасы предприятиеләрен, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләрен экспорт эшчәнлегенә җәлеп итү;

Татарстан Республикасы экспортерлары каталогын булдыру һәм алып бару;

экспортка юнәлтелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру.

Моннан тыш, Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларының «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» ККМКнең Экспортка ярдәм үзәгендә дәүләт ярдәме чараларыннан файдалану мөмкинлеге бар. Үзәк түбәндәге хезмәтләрне күрсәтә:

экспорт эшчәнлеге мәсьәләләре буенча консультация бирү;

экспорт контрактын әзерләүдә һәм (яисә) экспертизалауда ярдәм итү;

товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) чит илләргә чыгару өчен тышкы базарларда куела торган мәҗбүри таләпләргә продукцияне туры китерүдә ярдәм итү (стандартлаштыру, сертификацияләү, кирәкле рөхсәтләр);

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен һәм аларга тиңләштерелгәнтоварларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне һәм  Россия Федерациясе территориясеннән читтә хокукый саклау бирелә торган предприятиеләрне индивидуальләштерү чараларын саклауны тәэмин итүдә һәм хокукларны рәсмиләштерүдә ярдәм итү;

потенциаль чит ил сатып алучыларын эзләүдә һәм сайлап алуда ярдәм итү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларының күргәзмә-ярминкә, мәгълүмат-консультация һәм башка чараларда катнашуын оештыру;

экспорт эшчәнлеге мәсьәләләре буенча семинарлар, вебинарлар, мастер-

классылар һәм башка мәгълүмати-консультация чаралары уздыру;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларын электрон сәүдә мәйданчыкларында урнаштыруда ярдәм итү;

экспорт эшчәнлеген үстерү буенча акселерация программаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларының катнашуын оештыру;

конференцияләр, форумнар, «түгәрәк өстәлләр» һәм экспорт эшчәнлеген популярлаштыруга юнәлтелгән башка чаралар уздыру.

Экспортка ярдәм итү һәм стимуллаштыру чаралары инде экспорт тәҗрибәсенә ия булган яисә экспорт эшчәнлеген башлауга югары әзерлек стадиясендә булган оешмалар өчен чит ил базарларына чыгуга практик һәм максатчан ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелергә тиеш.

«Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» ККМКнең Экспортка ярдәм үзәге Alibaba, Epinduo, ЛеснойРесурс.рф, Topfranchise, Trendyol һәм Turkishexporter кебек халыкара маркетплейсларында эшкуарлар продукциясен урнаштыру буенча хезмәт күрсәтә.

Маркетплейслар элеккечә үк сатучылар тарафыннан зур үсеш алган бик нәтиҗәле канал дип бәяләнә: сатучыларның 64 проценты 2022 елда маркетплейсларда үз сатуларының күләме артуы турында хәбәр итә. Тармак үсешенә 2022 елның мартында төзелгән «Маркетплейс.Легко» автоном коммерцияле булмаган оешмасының электрон сәүдә үзәге шактый өлеш кертте. Интернет-сәүдәнең динамик үсеше шулай ук Татарстан Республикасында Wildberries, OZON, KazanExpress компанияләренең инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру белән дәраслана.

Татарстан Республикасының вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисадый вәкиллекләре эше тышкы икътисадый мәнфәгатьләрне тәэмин итүнең нәтиҗәле коралы булып тора.

2022 елда беренче тапкыр чимал булмаган энергетикага карамаган экспорт өлкәсендә эре сәнәгать предприятиеләре өчен «Ел экспорты» конкурсы үткәрелде. «Сәнәгать өлкәсендә иң яхшы предприятие-экспортер» номинациясендә «КАМАЗ» ГАЖ, «Сәнәгать продукциясе экспорты өлкәсендә ел алдынгысы» номинациясендә «Нәфис Косметикс» АЖ җиңүче дип танылды.

Россия Федерациясе субъектларында ел саен «Ел экспортеры» конкурсын уздыру РЭС 2.0 – «Россия Федерациясе субъектының икътисадый актив халкы һәм яшьләре арасында экспорт эшчәнлеген популярлаштыру механизмнарын булдыру һәм үстерү» кораллары исемлегенә керә.

Шул ук вакытта тышкы икътисадый хезмәттәшлекне үстерүдә Татарстан Республикасында югары дәрәҗәдәге халыкара чаралар уздыру мөһим роль уйный.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан даими нигездә «Час с с торгпредом» форматында Россия Федерациясенең сәүдә вәкилләре катнашында видео-конференц-элемтә режимында чаралар уздырыла.

Конгресс-күргәзмә чараларын үткәрү Татарстан Республикасының инвестиция потенциалын алга җибәрүдә мөһим юнәлеш булып тора.

2022 елның 19 – 21 маенда «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII Халыкара икътисадый саммиты уздырылды, анда 64 илдән 6 388 кунак катнашты.

13 ел дәвамында «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммиты халыкара оешмалар, дәүләт хакимияте органнары, финанс институтлары, илчелекләр, парламентлар депутатлары, әйдәп баручы инвесторлар һәм бизнесменнар, Россия һәм чит ил компанияләренең топ-менеджерларын берләштерә. Саммит үзен яңа элемтәләр урнаштыру өчен уңышлы бизнес платформа сыйфатында күрсәтте, шулай ук икътисадый мөмкинлекләрне һәм инвестицион потенциалны тәкъдир итү өчен ярдәм булды. Саммитның төп темалары ислам финанслары һәм партнерлык банкингы, хәләл индустрия, яшьләр дипломатиясе, экспорт, эшкуарлык һәм инвестицияләр үсеше булды. Чара кысаларында Russia Halal Expo 2022 күргәзмәсе, Машина төзелеше кластерлы форумы, Бөтендөнья хәләл көне һәм Идел Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар узды.

2023 елның октябре Россия Федерациясе Президентының «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы турында» 2023 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы Указы нигезендә чарага федераль статус бирелде.

2022 елның сентябрендә Kazan Digital Week Халыкара форумы булды, ул ел саен белгечләрнең эшлекле аралашуын үстерү максатларында уздырыла.

## IV. Экспорт үсешенең перспектив юнәлешләре

Бизнесны яңа сату базарларына, шул исәптән экспортка чыгару өчен шартлар тудыру:

«Татарстан Республикасы  Эшкуарлыкка ярдәм фонды» ККМКнең Экспортка ярдәм үзәге чараларында гамәлдәге һәм потенциаль экспортерларның катнашуын тәэмин итү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларының «2024 – 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» дәүләт программасы чараларында (чаралар планында) катнашуын тәэмин итү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларының инвестицион активлыгына мониторинг үткәрү.

Махсуслаштырылган экспорт инфраструктурасын үстерү.

Экспортка чыгарыла торган товарларны чыгару мөмкинлеген тудыра торган мөһим фактор – ул транспорт-логистика инфраструктурасының үсеше.

Логистика үсешенең гомуми векторы цифрлаштыру ягына юнәлдерелгән.

Цифралы технологияләр сатып алулар, товарлар кайтарту чылбырлары белән нәтиҗәле идарә итәргә, саклауны оптимальләштерергә ярдәм итәчәк.

Электрон документлар әйләнешенә аерым игътибар бирергә кирәк. Бу цифралы логистиканың иң төп элементы. Йөк машиналары белән ташуларны оештырганда электрон документлар әйләнеше логистика челтәренең барлык дәрәҗәләрендә мәгълүмати агымнар белән идарә итүнең инновацион технологиясе буларак цифралы логистиканы үстерүгә алшартлар тудыра.

Логистик процесслар белән идарә итү өчен яңа мөмкинлекләр бердәм мәгълүмати киңлекне ачарга ярдәм итәчәк.

Бүген экспорт эшчәнлеге тотрыклылык артуның һәм икътисадый үсеш

динамизмы үсешенең иң мөһим факторларыннан берсе буларак карала. Дөньяның 100 илендә махсус дәүләт, ярымдәүләт һәм дәүләтнеке булмаган институтлар булдырылды һәм эшли, аларның экспортерларга финанс һәм финанс булмаган ярдәм күрсәтергә вәкаләте бар. Дөньякүләм практикада, кагыйдә буларак, турыдан-туры чит ил инвестицияләрен җәлеп итүнең һәм кабул итүче ил экспортын үстерүнең югары корреляциясе күзәтелүен исәпкә алып, хәзерге вакытта гамәлдә булган милли оешмаларның абсолют күпчелеге экспортны яклау һәм турыдан-туры чит ил инвестицияләрен җәлеп итү функцияләрен берләштерә.

Экспортка ярдәм итү буенча мөһим бурыч экспортны гамәлгә ашыру өчен кирәкле барлык процедуралар мөстәкыйль рәвештә, арадашчылардан башка, шул исәптән экспортерларның профессионализмын күтәрү, ярдәмче мәгълүмат сервислары экспортерларына эшләү һәм бирү хисабына теләсә нинди экспортер тарафыннан башкарылырга мөмкин булсын өчен шартлар тудыру.

Әлеге өлкәдә төп чараларның берсе булып сервислар экспортына мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча интернет-портал базасында үсеш тора, аңа түбәндәгеләр кирә:

экспертер өчен, законнар таләпләрен үтәүне дә кертеп, экспорт белән тәэмин итүне гамәлгә ашыруга бәйле операцияләрнең бөтен эзлеклелеген, шулай ук товарлар ташуны оештыруны җентекләп тасвирлый торган кулланма;

экспортер өчен бердәм тәрәзәгә берләштерелгән электрон сервислар комплексы (таможня декларацияләве, таможня түләүләре, дәүләт пошлиналары түләү, лицензияләр алу, килеп чыгышлы сертификатлар алу, башка рөхсәт документларын алу, экспортны финанс яклавы өчен запрос, Россиядә һәм чит илдә экспорт өчен административ каршылыклар турында мәгълүмат бирү, экспорт мәсьәләләре буенча оператив консультацияләр сервисы, поставка узуны күзәтү сервисы, товарны чыгару өчен транспорт эзләү сервисы, шулай ук, кирәк булган очракта, экспортерлар кызыксынган башка сервислар).

Татарстан Республикасында экспорт үсешенең перспектив географик юнәлешләре 3 нче таблицада күрсәтелде.

3 нче таблица

| Макротөбәк | Дәүләтләр – сәүдә партнерлары | Чит илгә чыгарыла торган продукция | Экспорт потенциалы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Таможня берлеге һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре | Казахстан Республикасы, Үзбәкстан Республикасы, Беларусь Республикасы, Кыргызстан Республикасы, Әзәрбәйҗан, Әрмәнстан | Машина-техника продукциясе, азык-төлек товарлары, сәнәгать материаллары, киң кулланыштагы товарлар | Экспортны үстерү өчен түбәндәгеләр алшарт булып тора: интеграция процесслары гамәле, уртак яисә якын чикләр, тыгыз тарихи, социаль-мәдәни, икътисадый элемтәләр, үсә торган җирле базарлар, уңайлы транспорт-географик урнашу урыны бар. Нефть продуктлары, |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | химия продуктлары, транспорт хезмәтләре, машина төзелеше продукциясе, автомобильләр һәм комплектлау әйберләре, тимер юл техникасы, фармацевтика про-укциясе зур экспорт потенциалына ия. |
| Көньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк Азия илләре | Кытай Халык Республикасы, Һиндстан Республикасы, Вьетнам Социалистик Республикасы, Индонезия Республикасы һәм Малайзия | Югары чималлы товарлар | Россия Федерациясе белән Азиянең иң зур илләре, Кытай Халык Республикасы, Һиндстан Республикасы арасында икътисадый хезмәттәшлекнең төрле рәвешләрендә һәм сәүдә итүдә нинди дә булса дискриминация чикләүләре булмау әлеге дәүләтләр белән хезмәттәшлекне үстерүгә йогынты ясый. Тоннажлы товарларны (беренчел авыл хуҗалыгы продукциясе, сәнәгать чималы һәм ярымфабрикатлар) күпләп сатуны үстерү өчен ярдәм итүче факт булып макротөбәкнең географик ераклыгы тора. Нефть продуктлары, ашламалар, машина төзелеше продукциясе, целлюлоза-кәгазь продукциясе, пластмассадан резина-техник эшләнмәләр, IT-сектор хезмәтләре, туристлык хезмәтләре зур экспорт потенциалы булып тора. |
| Якын Көнчыгыш һәм Төньяк Африка илләре | Иран Ислам Респуб-ликасы, Төркия Рес-публикасы, Сирия Гарәп Республикасы, Мисыр, Марокко Корольлеге һәм | Югары дәрәҗәдә эшкәртелгән нефть продуктлары, азык-төлек, металлургия продукциясе, химия һәм урман сәнәгате | Экспорт күләмнәрен арттыру перспективалары макротөбәк илләренең икътисадый үсешенең шактый зур потенциалы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Берләшкән Гарәп Әмирлекләре | комплекслары продукциясе | белән һәм продукциянең аерым төркемнәре (азык-төлек, урман-кәгазь товарлары, металл) кытлыгының табигый һәм социаль-икътисадый сәбәпләре аркасында сакланып калу белән билгеләнә.<br>Азык-төлек продуктлары (майлы азык-төлек, кош ите), пило-материаллар, нефть химиясе чималы, ашламалар, агач плиталар һәм фанера, азык, хәләл фармацевтик препаратлар шактый зур экспорт потенциалына ия. |
| Үзәк һәм Көньяк Африка илләре | Ангола Респуб-ликасы, Нигерия Федератив Респуб-ликасы, Эфиопия Федератив Демо-кратик Республикасы | Ашлык, ашлама, машина төзелеше | Экспорт үсеше перспективалары Африка илләренең күпчелегенең икътисадый үсеш дәрәҗәсе һәм базарның ераклыгы белән чикләнә.<br>Нефть продуктлары, ашламалар, азык-төлек продуктлары, химия тармагы продукциясе, машина төзелеше продукциясе зур экспорт потенциалына ия. |
| Төньяк, Үзәк һәм Латин Америкасы илләре | Бразилия Федератив Республикасы, Мек-сика Кушма Штат-лары, Аргентина | Ашламалар, нефть продуктлары | Бу макротөбәк илләренә экспортның күпчелек перспектив товарлары буенча, башка илләрдән тәэмин итүчеләрнең югары көндәшлеге булганда, дефицит юк.<br>Нефть продуктлары, ашламалар зур экспорт потенциалына ия. |

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясенә кушымта

## 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы экспортын үстерүнең төп күрсәткечләрен фаразлау күрсәткечләре

Максат: 2030 елга «Чимал булмаган энергетикага карамаган товарлар экспортының реаль үсеше 2020 ел күрсәткече белән чагыштырганда кимендә 70 процент» дигән күрсәткечкә ирешү

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч тибы (максатчан, төп, өстәмә) | Үлчәү берәмлеге | 2020 елның төп күрсәткече | | Гамәлгә ашыру еллары буенча планлаштырылган күрсәткечләр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | күрсәткече | датасы | 2022 ел | 2024 ел | 2030 ел |
| 1. | Чимал булмаган энергетикага карамаган экспортның реаль үсеше (чагыштырма бәяләрдә, млн. АКШ долларында) | максатчан | млн. АКШ доллары | 2 678,7 | 31.12.2020 | 2 917,1 | 3 401,9 | 4 553,79 |
| 2. | Экспортер илләрнең санын арттыру (2022 елда фактта кимүне исәпкә алып, арта бара торган йомгак белән) | өстәмә | берәмлек | 139 | 31.12.2020 | 141 | 143 | 145 |
| 3. | Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау күләмен арттыру (чагыштырма бәяләрдә, млн. АКШ долларында) | өстәмә | млн. АКШ доллары | 286,1 | 31.12.2020 | 0,0 | 287,2 | 486,37 |
| 4. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган экспортерлар санын арттыру | өстәмә | берәмлек | 1 001 | 31.12.2020 | 1 104 | 1 200 | 1 150 |

______________________